# IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ XII СЕССИЯСЕ

## К А Р А Р № 65

Мөслим авылы «15» ноябрь 2021 ел

**«Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәтне биләү һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль милек исемлеген раслау турында» 2016 елның 26 сентябрендәге 50 номерлы Мөслим муниципаль районы Советы карары белән расланган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәтне биләү һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль милек исемлегенә өстәмәләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Уставының 37 статьясы нигезендә һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларының торак булмаган биналарга ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәтне биләү һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль милек исемлеген раслау турында» 2016 елның 26 сентябрендәге 50 номерлы Мөслим муниципаль районы Советы карарына түбәндәге өстәмәләр кертергә:

1.1. Әлеге карарның кушымтасы нигезендә түбәндәге объектларны муниципаль милек исемлегенә кертергә һәм расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Мөслим муниципаль районы
Башлыгы урынбасары,
Мөслим муниципаль районы
Советы Рәисе урынбасары А.М. Әхмәтҗанов

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Советының 2021 елның
15 ноябрендәге 65 номерлы
карарына кушымта

| № т/б | Мөлкәт реестрындагы номер | Объектның адресы (урыны) | Күчемсез милек объектының төре; күчмә милек | Күчемсез милек яки аның өлеше турында мәгълүмат | | | | | | | Күчмә милек турында мәгълүмат | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Кадастр номеры | | Күчемсез милек дәүләт кадастры белешмәләре нигезендә күчемсез милек объектының бер өлеше номеры | Күчемсез милек объектының төп характеристикасы | | | Исәпкә алу объектының исеме | Тибы: җиһазлар, машиналар, механизмнар, урнаштыру, транспорт чаралары, инвентарь, инструментлар һ. б. | Дәүләт теркәү билгесе (булганда) | Исәпкә алу объектының исеме | Маркасы, моделе | Чыгару елы | Күчемсез милек объектының, шул исәптән объект урнашкан җир кишәрлегенең кадастр номеры |
| | | | | Номер | Тибы (кадастр, шартлы, искергән) | | Тибы (мәйдан- җир участоклары, биналар, бүлмәләр өчен; озынлык, күләм, мәйдан, тирәнлек һ. б. - корылмалар өчен; - проект документлары нигезендә озынлык, күләм, мәйдан, тирәнлек һ. б. - төзелеп бетмәгән төзелеш объектлары өчен. | Фактта гы әһәмияте/ проектланторган әһәмият (төзелеп бетмәгән төзелеш объектлары өчен) | Үлчәү берәмлеге (мәйданы өчен-кв. м; озынлыгы-м; тирәнлек-м; күләм-куб. м | | | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 | 28 |
| 1 | | ТР, Мөслим районы, Мөслим авылы, Гагарин ур., 9А | 1972 елда төзелгән йогышлы авырулар хастаханәсе бинасы | 16:29:060150:54 | кадастр | | 317,9 | | кв.м. | | | | | | | |
| 2 | | ТР, Мөслим районы, Мөслим авылы, Гагарин ур., 7А | 2003 елда төзелгән азык-төлек блогы бинасы | 16:29:060151:78 | кадастр | | 181,2 | | кв.м. | | | | | | | |